ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 404-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.А. Якунин, К.Ә. Ногаев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 404-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 23 марты
№ 1893-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.А. Якунин, К.Ә. Ногаев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында**

**Татарстан Республикасы**
**ЗАКОНЫ**

**1 статья**

«Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2022 елның 26 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда «№ 83 (I өлеш)» сүзләреннән соң «$29^3$ статьяның 2 һәм 3 пунктларының («Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору, Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану һәм 2023 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2022 елның 21 ноябрендәге 448-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 36 – 38 өлешләре нигезендә бирелә торган махсус казна кредитларына карата),» сүзләрен өстәргә;

2) 4 статьяда:
а) 2 өлештә «бюджет ассигнованиеләре суммасына» сүзләреннән соң «, махсус казна кредитлары суммасына» сүзләрен өстәргә;
б) 3 өлештә «югарырак булмаган суммага» сүзләреннән соң «, махсус казна кредитлары суммасына» сүзләрен өстәргә;

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы Бюджет кодексын «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору, Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану һәм 2023 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 23 февралендәге 373-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба – Федераль закон) туры китерү максатыннан эшләнде.

Федераль законда 2023 елда РФ бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен җайга сала торган кайбер нигезләмәләр төгәлләштерелә шул исәптән Федераль казначылыкның, федераль бюджетның бердәм счетында калган акчалар белән идарә операцияләрен гамәлгә ашыру кысаларында, 2023 елда РФ субъектлары бюджетларына РФ Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә федераль бюджетның бердәм счетында вакытлыча тотылмый торган акчалар исәбеннән 15 елга, файдаланган өчен елына 3 процент белән һәм гомуми күләме 250 миллиардка кадәр, вакытыннан алда түләп бетерү мөмкинлеге белән, махсус казна кредитлары бирү хокукы билгеләнә.

Бер үк вакытта Россия Федерациясе субъектларының бюджет законнарында билгеләнгән бюджет кытлыгын, дәүләт (муниципаль) бурычын махсус казна кредитлары суммасына арттыру мөмкинлеге дә карала.

Федераль законда шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының махсус казна счетларына кагылышла кайбер нигезләмәләрен туктатып тору каралган.

Бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә, закон проекты белән «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.